Кукмара муниципаль районы Зур Кукмара
авыл җирлеге Советы

КАРАР

«01» июль, 2022 ел № 27

Кукмара муниципаль районы Зур Кукмара авыл җирлегенең Янсыбы торак пунктында «Кукмара муниципаль районы Зур Кукмара авыл җирлегенең Янсыбы авылында үзара салым акчаларын кертү һәм куллану мәсьәләсе буенча гражданнар җыены нәтиҗәләре турында» 2021 елның 27 ноябрендәге 1 номерлы гражданнар җыены карарына үзгәрешләр кертү мәсьәләсе буенча гражданнар җыены үткәрүне билгеләү турында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы һәм Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районы Зур Кукмара авыл җирлеге муниципаль берәмлеге Уставының 22 статьясы нигезендә Зур Кукмара авыл җирлеге Советы

КАРАР БИРДЕ:

1. 2022 елның 11 июленә 18 сәгать 00 минутка «Кукмара муниципаль районы Зур Кукмара авыл җирлегенең Янсыбы авылында үзара салым акчаларын кертү һәм куллану мәсьәләсе буенча гражданнар җыены нәтиҗәләре турында» 2021 елның 27 ноябрендәге 1 номерлы Янсыбы авылы гражданнар җыены карарына

- Янцобино авылында һәйкәлне ремонтлау, проект-смета документациясен эшләү сүзләрен

- һәйкәлне ремонтлау һәм карап тоту, проект-смета документациясен эшләү сүзләренә алмаштырырга

Халык җыенын Янсыбы авылының И.Хәйретдинов урамы, 54 нче йорт адресындагы авыл клубы янәшәсендә үткәрергә.

2. Гражданнар җыенына чыгарыла торган мәсьәләне расларга:

«Кукмара муниципаль районы Зур Кукмара авыл җирлегенең Янсыбы авылында үзара салым акчаларын кертү һәм куллану мәсьәләсе буенча гражданнар җыены нәтиҗәләре турында» 2021 елның 27 ноябрендәге 1 номерлы Янсыбы авылы гражданнар җыены карарына түбәндәге үзгәрешләрне кертү белән килешәсезме:

.

«Янсыбы авылында һәйкәлне ремонтлау, проект-смета документациясен эшләү» сүзләрен

- һәйкәл урнаштыру, ремонтлау һәм карап тоту, проект-смета документациясен эшләү сүзләренә алмаштырырга

«РИЗА» «КАРШЫ»

Әлеге карарны авыл җирлеге территориясендә урнашкан мәгълүмат стендларында, Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында (pravo.tatarstan.ru) бастырып чыгарырга, шулай ук «Интернет» мәгълүмат-коммуникация челтәрендә Кукмара муниципаль районының рәсми сайтында урнаштырырга.

Җирлек башлыгы Р.Р. Хәнәфиев